КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.03.2026 № 138-П

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Казан шәһәрендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында» 2019 елның 09 октябрендәге 114-П номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Жуковский урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан «1925-1937 елларда Шәрәф Галимҗан яшәгән йорт» региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре тасвирламасындагы төрлечә укылуларны бетерү максатларында,

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Казан шәһәрендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында» 2019 елның 09 октябрендәге 114-П номерлы боерыгына 1 нче кушымтаның 41 пунктын (Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2020 елның 7 апрелендәге 55-П номерлы, 2022 елның 2 февралендәге 9-П номерлы, 2022 елның 24 мартындагы 56-П номерлы, 2022 елның 27 июлендәге 215-П номерлы, 2023 елның 15 июнендәге 239-П номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тоту өчен үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н. Гущин